КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 июль г.Казань № 526

**2025 елда урман хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм тәҗрибә алмашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы делегациясе составында Беларусь Республикасына визитта катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2025 елда урман хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм тәҗрибә алмашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы делегациясе составында Беларусь Республикасына визитта катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 18 июль, 526 нчы карары белән расланды

2025 елда урман хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм тәҗрибә алмашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы делегациясе составында Беларусь Республикасына визитта катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2025 елда урман хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм тәҗрибә алмашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы (алга таба - муниципаль берәмлек) бюджетына Татарстан Республикасы делегациясе составында Беларусь Республикасына визитта катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар (алга таба - башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба - Министрлык) җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар бирү шарты - Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба - килешү) төзү.

4. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) Министрлык билгеләгән срокларда түбәндәге документларны Министрлыкка тапшыра:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗны финанс-икътисад ягыннан нигезләү теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявка (алга таба – заявка);

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ.

5. Вәкаләтле органыннан кергән документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә карап тикшерелә. Документларны карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлык башка бюджетара трансфертлар бирү турында йә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бу турыда, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, вәкаләтле органга хәбәр итә.

Вәкаләтле орган, бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

Яңадан бирелгән заявкаларын карап тикшерү тәртибе беренче тапкыр бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе белән охшаш.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү;

бу Тәртипнең 4 пунктында каралган документларның тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмавы).

7. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык белән вәкаләтле орган арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә (алга таба - килешүнең бертип формасы).

8. Башка бюджетара трансферт күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.

9. Башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе - урман хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм тәҗрибә алмашу максатларында Беларусь Республикасына визитта катнашу белән бәйле чыгымнар буенча бурыч булмау.

10. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар нәтиҗәлелеген фактта ирешелгән күрсәткечләре белән чагыштыру аша гамәлгә ашырыла.

11. Башка бюджетара трансфертлар килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

12. Вәкаләтле орган Министрлыкка финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисапны килешүнең бертип рәвешенә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча килешү төзүдә каралган срокларда тапшыра.

13. Вәкаләтле орган тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатсыз файдаланган өчен законнар нигезендә җавап тота.

14. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

муниципаль берәмлек тарафыннан Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылу;

вәкаләтле орган килешүдә билгеләнгән срокта финанслау максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турындагы хисапны һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турындагы хисапны тапшырмау;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә билгеләнгән срокларда башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәү.

15. Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланылмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

16. 2026 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчасы 2026 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

17. Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.